# КАРАР

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлеге составына керүче Красный Ключ торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2022 елның 25 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 24-25 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Красный Ключ авыл җирлеге Красный Ключ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, һәрби хезмәттәге, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш; 2 нче төркем инвалидларга 50 % түләү белән, 300 сум күләмендә 2023 елда үзара салым кертү белән килешәсезме һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны:

- Красный Ключ поселогындагы "Сугышчылар" Мемориалын реконструкцияләүгә (брусчаткадан өслекне ремонтлау, яктырту баганаларын алыштыру, яктырткычларны алыштыру);
- зиратны төзекләндерү (зират территориясен койма белән әйләндереп алу, зират территориясендә агачларны санитар кисеп алу, төпләү)

"ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 2168 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар саны 1145 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 631 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 514 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлеге составына керүче Красный Ключ торак пунктында гражданнар җыенын узды дип таныргa,халык җыены нәтиҗәләре - дөрес.
2. Түбән Кама муниципаль районының Красный Ключ авыл җирлеге Красный Ключ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, һәрби хезмәттәге, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш; 2 нче төркем инвалидларына, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерларга, күпбалалы гаиләләргә 50 % түләү белән, 500 сум күләмендә 2023 елда үзара салым кертү белән килешәсезме һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- алынган акчаларның 50 процентын Красный Ключ поселогындагы "Сугышчылар" Мемориалын реконструкцияләүгә җибәрергә (подряд шартнамәләрен барлык эш төрләре буенча түләү);

- алынган акчаларның 50%ын зиратны төзекләндерүгә (зират территориясен койма белән әйләндереп алу, зират территориясендә агачларны санитар кисеп алу, төпләү) юнәлтергә.

“ӘЙЕ ЮК»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Красный Ключ авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Красный Ключ авыл җирлеге башлыгы И.К. Зәйнетдинов